**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 № 531

**2021 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында» үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 2009 ел, 14 декабрь, 854 нче карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

- Тәтеш муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә теркәлгән норматив чыгымнарны(1 нче номерлы кушымта);

- балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны 0,5 күләмендә төзәтү коэффициенты.

2. Тәтеш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
23 октябрендәге 531 номерлы
Карарына кушымта

**2021 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының сәнгать эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 елга 1 укучыга исәпләнгән сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өч еллык уку вакыты | Дүрт еллык уку вакыты | Биш еллык уку вакыты | Җиде еллык уку вакыты | Башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | Шәһәр җире | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Рәсем сәнгате | Шәһәр җире | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Бию сәнгате | Шәһәр җире | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җире | | | 25 592 | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җире | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җире | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җире | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |